РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
«МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

улица Ленина, дом 52 А, пгт. Рыбная Слобода, 422650
Ленин урамы, 52 А йорты, Балык Бистәсе штп., 422650
Тел.: (8-84361) 2-21-92, факс: (8-84361) 2-21-26. E-mail: sloboda.ege@rambler.ru

**Балык Бистәсе муниципаль районы "Балык Бистәсе 2нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбе" МГББУ укытучысы Хафизова Рәсимә Миннулла кызының педагогик эшчәнлегенә бәяләмә.**

Хафизова Рәсимә Миннулла кызы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе 2 нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.Шушы вакыт эчендә ул үзен балаларны,эшен яратучы оста педагог итеп танытты.Аның дәресләре укучыларда зур кызыксыну уята, чөнки Рәсимә Миннулла кызы дәресләргә бай материал туплап, зур хәзерлек белән керә.Укытучы үз- үзен тотышы, эмоциональ матур сөйләме белән укучыларда туган җиргә, туган телгә мәхәббәт, ата-анага, өлкәннәргә карата шәфкатьлелек хисләре тәрбияли.Ул укучыларның мөстәкыйль рәвештә фикерләү сәләтен үстерүгә ,грамоталы язуларына һәм сәнгатьле укуларына нык игътибар итә. Балаларга шәхес буларак каравы нәтиҗәсендә Рәсимә Миннулла кызының укучылар арасында авторитеты зур.Укучылар аны яраталар, үз итәләр.Ул аларның өлкән дусты да,киңәшчесе дә,сердәше дә.

Рәсимә Миннулла кызы районның татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен ачык дәресләр, сыйныфтан тыш чаралар күрсәтә, семинарларда чыгышлар ясый.

2015-2016 нчы уку елында район күләмендә үткәрелгән 6 б сыйныфында "Чын дуслык" сыйныф сәгате, 2б сыйныфында "Апрель ае", 3 б сыйныфында "Нинди ул Татарстан?" дәресләре укытучыны үз эшенең остасы итеп исбатлады.

Рәсимә Миннулловна үзенең иҗат лабораториясен баетуга күп көч куя.Аның иҗат лабораториясенә китаплар, сәләтле һәм авыр үзләштерүче укучылар өчен индивидуаль карточкалар, дәрес эшкәртмәләре иҗади эшләр тупланган.Ул укучыларны фән белән кызыксынуларын арттыру буенча уңышлы эшли .Үз-үзенә таләпчән,хезмәттәшләренә ихтирамлы булганы өчен аны укытучылар,укучылар,эти –әниләр хөрмәт итәләр.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының "Мәгариф
бүлеге муниципаль казна
учреждениесы» башлыгы: И.М.Садыйков